ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 522-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.К. Хамаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 522-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2352-VI ДС

522-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутаты
А.К. Хамаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяда:
а) 1 өлештә:
өченче абзацта «республика программаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын» сүзләренә алмаштырырга;
түбәндәге эчтәлекле өстәмә кырык өченче яңа абзац өстәргә:
«әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру;»;
кырык өченче абзацны кырык дүртенче абзац дип санарга;
б) 2 өлештә «кырык өченче» сүзләрен «кырык дүртенче» сүзләренә алмаштырырга;

2) 50 статьяда:
а) 1 өлештә «шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) күрсәткечләренең дәүләт фондын төзү һәм аннан файдалану» сүзләрен «әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт

мәгълүмат системасын төзү, аннан файдалану һәм аны үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, шушы статья белән үз көчләренә керүнең бүтән сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче – бишенче абзацлары һәм «б» пунктчасы 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 450-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

Күрсәтелгән Федераль закон белән «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон әйләнә-тирә мохит торышының федераль мәгълүмат системасы эшчәнлеге мәсьәләләрен җайга сала торган нигезләмәләр өстәлде, ул Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарын, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарын, җирле үзидарә органнарын, оешмаларны һәм халыкны әйләнә-тирә мохитнең торышы турында мәгълүмат белән тәэмин итү, мондый мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм анализлау, шулай ук әйләнә-тирә мохитнең торышын бәяләү һәм табигать факторлары һәм (яисә) антропоген факторлар йогынтысы астында аның үзгәрешләрен фаразлау максатларында төзелә.

Шул ук вакытта «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның дәүләт экология мониторингы күрсәткечләренең дәүләт фонды эшчәнлеге мәсьәләләренә багышланган $63^2$ статьясы үз көчен югалткан дип таныла.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Экология кодексында федераль законнардагы үзгәрешләрне чагылдыру тәкъдим ителә.

Аерым алганда, закон проекты белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының экология өлкәсендәге вәкаләтләре исемлеген әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру вәкаләте белән тулыландыру каралган. Шулай ук Татарстан Республикасы Экология кодексыннан дәүләт экология мониторингы күрсәткечләренең дәүләт фонды төшенчәсе төшереп калдырыла.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, аларга үзгәрешләр кертүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 һәм 50 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.